
Кулланучы хәбәрләре

# Җиде кат үлчә, бер кат кис




**«Күптән түгел урамда бер яшелчә кибетеннән җиләк-җимеш сатып алдым. Сатучының үлчәве товарны күпме үлчәгәнен кеше күрмәслек итеп урнаштырылган иде. Җиләк-җимеш салынган сумканы күтәреп карагач, аның авырлыгы җитми кебек тоелды. Товарны яңадан үлчәгез дигән үтенечемне сатучы кире какты. Миңа җиләк-җимешне аңа кире бирүдән башка чара калмады. Азык-төлек товарлары белән сату итүченең контроль үлчәве булырга тиешме?**

**Надежда Р.»**

Әлеге сорауга Татарстан Республикасы Гигиена һәм эпидемиология белгечләре җавап бирә.

– РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 31 декабрендәге 2463нче карары белән расланган Ваклап сатып алу-сату килешүе буенча товар сату кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә, товар үлчәнә торган булса, аны саткан вакытта сатучы төзек хәлдәге һәм үлчәү берәмлекләрен тәэмин итү турындагы Россия Федерациясе законы таләбенә туры килгән үлчәү чаралары кулланырга бурычлы.

**Әгәр товарның үлчәү берәмлеге (авырлыгы, озынлыгы һ.б.) өчен бәя сатучы тарафыннан билгеләнсә һәм товар шул нигездә сатылса, ул чагында кулланучы тарафыннан бәянең дөреслеген тикшерү һәм товарны сатып алган җирдә үлчәү өчен уңайлы урында төзек хәлдәге һәм үлчәү берәмлекләрен тәэмин итү турындагы Россия Федерациясе законы таләбенә туры килгән үлчәү чаралары урнаштырылырга тиеш.**

# Килешүне үтәмәдеңме? Пени түлә!

**«Кибеттә ике атна эчендә китерү шарты белән бала коляскасына заказ биргән идем. Бер ай узды, ә товарны китерүче юк, гәрчә килешү акчаны тулысынча алдан түләп төзелсә дә. Килешүдә күрсәтелмәгән очракта, пенига өметләнеп буламы?**

**Ирина П.»**

**Әлеге сорауга Роспотребнадзор белгечләре җавап бирә.**

– Сезнең очрак «Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ Законының 23.1 маддәсе белән җайга салына: әгәр сатып алучы, алдан түләнгән сумманы алганнан соң товарны үз вакытында кулланучыга тапшырмаса, бу очракта сатып алучы акчасы түләнгән товарны аның тарафыннан билгеләнгән яңа срокта тапшыруны яки товар өчен алдан түләнгән сумманы кире кайтаруны таләп итәргә хокуклы



**Шулай ук сатып алу-сату турындагы килешүдә билгеләнгән, товарны кулланучыга тапшыру срогы бозылган очракта, сатып алучы аңа үз вакытында түләмәгән һәр көн өчен пени түли. Аның күләме товар өчен алдан түләнгән сумма процентының яртысын тәшкил итә.**
**Пени сатып алу-сату килешүе буенча товар кулланучыга тапшырылырга тиешле көннән товарны тапшырган яки кулланучыга алдан түләнгән сумманы кире кайтарган көннән алына. Шул ук вакытта, пени күләме товар өчен алдан түләнгән суммадан артып китмәскә тиеш.**

Сезнең очракта исә, хәтта әлеге шарт килешүдә урын алмаган очракта да, сатучыдан пени түләүне таләп итәргә хакыгыз бар

**ЭНЕРГЕТИКЛАР ЯШЬ ТАЛАНТЛАРНЫ ЭЗЛӘҮЛӘРЕН ДӘВАМ ИТӘЛӘР!**

**ТАТЭНЕРГОСБЫТ**

**Яшь татарстанлыларның «Кояшлы куян – 2021» республика иҗади эшләр конкурсында катнашу өчен гариза бирергә һәм үзләренең истәлекле призларын алырга ике атна калды!**

Эшләр **5 октябрьгә** кадәр кабул ителәчәк һәм электрга сак карашны чагылдырырга тиеш. Конкурсантларның иҗади эшләре түбәндәге номинацияләрдә бәяләнәчәк: **«Иң яхшы рәсем» һәм «Иң яхшы хикәя яки шигырь».** Катнашучылар Татарстан Республикасында яшәүче 4 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге балалар була алалар.

Иң яхшы эшләрнең авторларын дипломнар һәм бүләкләр тапшырыр өчен Казанда ноябрь аенда узачак һәм Халыкара Энергия саклау көненә багышланган чарага чакырачаклар.



**Эшне шәхсән Татэнергосбытның офисына яки филиалларына алып килергә, шулай ук аны барлык кирәкле документлар белән компаниянең пресс-служба почтасына җибәрергә мөмкин: pressa@tatenergosbyt.ru**

Реклама

**БӨТЕН КЫЗЫКЛЫ МӘГЪЛҮМАТ БЕР УРЫНДА**



**shahrikazan.ru**

Реклама

**«Шәһри Казан. Язмыш» газетасының яңа саны!**




**«Шәһри Казан» газетасының 3 санына да язылсаң, «Язмыш»ны да укырсың.**
**Язылу бәясе – 1134 сум 48 тиен. (Индекс – П2395)**

Реклама 16+